**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Олы Тормы торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында гражданнар җыены карары**

**14 .12. 2023** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Турма авыл җирлегенең Олы Турма торак пунктында гражданнар җыены:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Турма авыл җирлегенең Олы Турма торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, күп балалы гаиләләрдән, гражданнардан тыш, 1000 (бер мең) сум акча кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итәргә чакырылганнар, махсус хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, иреклеләр) һәм аларның гаилә әгъзалары, атап әйткәндә: ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар; һәлак булган махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзалары (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, иреклеләр), атап әйткәндә: ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Олы Турма торак пунктында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш белән капланган чокыр ремонтлау, вак таш сатып алу, ташу, салу, эшләр, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү) ;

Олы Турма торак пунктында зиратның коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эш, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында " (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

**Җитәкче** **Н.Г. Салихов**